| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 2020 ел № _____

**2020 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру турында**

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыру һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган эшсез гражданнарны, беренче тапкыр эш эзләүче башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатларында, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба - «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, беренче тапкыр эш эзләүче башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны (алга таба - эшсез гражданнар) вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга.

- эшсез гражданнарга туры килә торган эшне эзләү максатларында, оештырыла торган эшләрнең төрләре һәм аларны үткәрү тәртибе, шартлары, режимнары һәм хезмәт хакы турында, шулай ук әлеге эшләрне башкарганда оешмалар тарафыннан бирелә торган ташламалар турында халыкка, шулай ук «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ндә теркәлгән затларга хәбәр итәргә;

- эш бирүчеләр белән эшсез гражданнарның вакытлыча мәшгульлеген оештыру турында килешүләр төзергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендәге эш бирүчеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ белән эшсез гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру буенча уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә;

- «Балтач районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән ашыгыч хезмәт килешүләре төзергә;

- эшсез гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру буенча уртак эшчәнлек турындагы килешү нигезендә оештырылган эш урыннарында гражданнарның мәшгульлеген тәэмин итәргә.

3. «2019 елда Балтач муниципаль районы буенча эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында» 2019 елның 29 апрелендәге 176 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatar.ru) халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов